СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

6 нчы март, 2024 ел Алабуга шәһәре №331

Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2020 елның 29 июлендәге 491 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Новая Кама» газетасында бастырып чыгарырга һәм муниципаль берәмлек сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: городелабуга.рф. адресы буенча дәүләт теркәвенә алганнан соң җиде эш көне эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар дәүләт теркәвенә алганнан соң рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына үзләренең хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

6. Кушымтаның 1 пунктындагы 1 пунктчасы, 2 пункты һәм 8 пунктындагы 1 пунктчасы 2024 елның 1 сетябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Советының 2024 елның 6 мартындагы
331 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр (алга таба - Устав)

1. Уставның 6 статьясында:

1) 1 өлешнең 26 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

2) 1 өлешнең 31 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

3) 1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 39 пункт белән тулыландырырга:

«39) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.».

2. Уставның 6.1 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;».

3. Уставның 29 статьясында:

1) 7 өлешнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2) 7 өлешнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында:

«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

3) 12 өлешне түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

«12. Район Советы депутаты чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында әлеге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны үтәмәгән очракта, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә җаваплылыктан азат ителә»;

4. Уставның 32 статьясында:

1) 1 өлешнең 16 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2) 1 өлешнең 28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы учреждениесе;».

5. Уставның 38 статьясын түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш белән тулыландырырга:

«4. Район Советы депутатының вәкаләтләре, әгәр депутат җитди сәбәпләрсез булмаса, алты ай рәттән Советының барлык утырышларында район Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»

6. Уставның 40 статьясындагы 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга.

7. Уставның 41 статьясында:

1) 5 өлешнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2) 5 өлешнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында:

«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

3) 7 өлешне түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

«7. Район Башлыгы чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында әлеге «Россия Федерациясендә җирле

үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны үтәмәгән очракта, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә җаваплылыктан азат ителә»;

8. Уставның 47 статьясында:

1) 1 өлешнең 24 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) җирле әһәмияттәге махсус саклангылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

2) 1 өлешнең 29 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру:».

3) 37 өлешне түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

«37) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата щлеге зыянны бетерүне оештыру.».

9. Уставның 44 статьясында:

1) 6 өлешнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 6 өлешнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында:

«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

10. Уставның 49 статьясындагы 7.1. өлешне түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

«7.1. Башкарма комитет җитәкчесе чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында әлеге

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны үтәмәгән очракта, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә җаваплылыктан азат ителә»;

11. Уставның 50 статьясындагы 2 өлешенең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга.

12. Уставның 52 статьясындагы беренче абзацының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Район Башлыгы белән килештереп билгели һәм Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын вазифаларыннан азат итә, алар арасында вазифаларны бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм район Башкарма комитетының башка хезмәткәрләре вазифасына билгеләп куя һәм ваззифаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;».

13. Уставның 53 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга.

14. Уставның 8 нче «Сайлау комиссиясе» бүлеге үз көчен югалткан дип танырга.

15. Уставның 77 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«77. Муниципаль хокукый актларның үз көченә керүе һәм игълан ителүе

1. Район Советының муниципаль хокукый актлары, әгәр актларда башкасы билгеләнмәгән булса, аларга кул куелган көннән үз көченә керә.

2. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы муниципаль норматив хокукый акт, муниципаль берәмлек оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

3. Район Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

4. Район Советының район Уставын кабул итү яки әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карарлар Федераль законда, әлеге Уставта билге ләнгән тәртиптә үз көченә керә.

5. Район Башлыгының хокукый актлары, әгәр шул ук актлар белән башкасы билгеләнмәгән булса, алар имзаланган көннән үз көченә керә.

6. Муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, гражданнар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга имза салынган көннән алып ун көн эчендә халыкка җиткерелә.

7. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары: исеме, аны кабул итү (имзалау), теркәү номеры, хокукый актка кул куйган вазифаи затның исеме, мөһере булырга тиеш.

8. Шулай ук җирле референдумны билгеләү турында, районның чикләрен үзгәртү, район Башлыгын һәм аның урынбасарларын сайлау мәсьәләләре буенча норматив булмаган хокукый актлар һәм законнар нигезендә башка актлар рәсми басылып чыгарга тиеш.

9. Муниципаль хокукый актларны игълан итүне гамәлгә ашыру:

- хокукый акт текстын муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: городелабуга.рф. электрон адресы буенча урнаштырыру (массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклык номеры: ЭЛ № 77-71579, 13.11.2017 ел).

10. Муниципаль норматив хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне игълан итүне гамәлгә ашыру:

1) массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырып чыгару:

- «Новая Кама» газетасында бастырып чыгару (массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклык номеры: ПИ № ФС7-4763, 30.11.2007 ел).

- «Алабуга Нуры» газетасында бастырып чыгару (массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклык номеры: ПИ № ТУ16-01026, 16.05.2013 ел).

- муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: городелабуга.рф. адресы буенча урнаштырыру (массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклыкның номеры: ЭЛ № 77-71579, 13.11.2017 ел)

2) «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» на (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән (басма) көннән 10 эш көне эчендә урнаштыру (Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында бирелгән таныклык номеры: ЭЛ № ФС 77-60244, 17.12.2014 ел).

11. Район Советы район бюджеты турындагы, аның үтәлеше турындагы, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турындагы карарлары, район Советы, район Башлыгы кабул иткән башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлардан яисә аларны тарату федераль законнар белән чикләнгән белешмәләр булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзалаган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

12. Законнар яисә әлеге Устав нигезендә рәсми басылып чыгуы мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны бастырган органнар яисә район җирле үзидарәсенең вазифаи затлары карары буенча бастырып чыгарылырга мөмкин.

13. Җирле үзидарә органнарының, муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хокукый статусын билгели торган кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкына законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә.

14. Уставның 84 статьясындагы 7 өлешендә:

1) өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.